ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЮГАРЫ ЯХШЫЙ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АКТАНЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
ВЕРХНЕЯХШЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

423765, Югары Яхшый авылы,
Яна урам, 17 нче йорт.
Тел.(885552)3-44-45.

423765, с. Верхнее Яхшеево, ул. Новая,
дом 17. Тел.(885552) 3-44-45.

E-mail vyah.akt@yandex.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**«16» ноябрь 2020 ел** **№ 9**

Югары Яхшый авыл җирлеге территориясендә гражданнарның
үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 7 августындагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге Советы карар бирә.

Карар:

1. Югары Яхшый авыл җирлеге территориясендә 2021 нче елда, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертүгә, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан кала, алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү турында:

- җирлектәге авылларда юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- җирлектәге авылларда урамнарны яктырту җиһазларын карап тоту;

- җирлектәге авылларда зиратларны ремонтлау һәм карап тоту;

- рәсми физкультура-сәламәтләндерү, мәдәният һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру.

2. Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында Югары Яхшый авыл җирлеге гражданнарының җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге гражданнарының җыены нәтиҗәсен Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында "авыл җирлеге"бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Югары Яхшый авыл җирлеге башлыгы: — Җ. Г. Зиннатуллина